Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 12 сентябре № 49/2

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Чистай Выселкасы авыл җирлеге
Советының 2020 елның 23 июлендәге 87/3
номерлы карарының гамәлдә булуын
туктатып тору турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон, Чистай муниципаль районының «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай Выселкасы авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 июлендәге 87/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай Выселкасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле бюджеты акчалары исәбеннән инвестиция проектлары буенча муниципаль гарантияләр бирү тәртибенең гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының Чистай Выселкасы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Чистай Выселкасы авыл җирлеге Башлыгы С.А. Ефимов